Драмматургларыбыз, театрларыбыз өчен бөтен ягы белән проблема рәвешендә торырга тиешле булган Шекспир мәктәбе турында пролетариатның бөек художнигы Максим Горький болай дигән иде: «Яңа дөньяны төзүче хәзерге заманның төп герое булырга тиеш, ә моның өчен, бу геройны тиешлечә көч белән һәм сүз яктылыгы белән сурәтләү өчен, бу әдәби форманың һичкем уза алмаган карт мастерларыннан һәм барысыннан да бигрәк Шекспирдан өйрәнергә кирәк».

Шекспир иҗаты безнең шәһәр театрларыбызда гына түгел, колхоз-совхоз театрларыбыз репертуарларында да мактаулы урын тота – социализмнан коммунизмга баручы хезмәт иясе массасын тәрбияләүдә зур хезмәт күрсәтеп килә.

Шекспир халык трагедиясен, халык зарын җырлаучы иде. Рус халкының бөек шагыйре А. С. Пушкин: «Шекспир трагедиясендә нәрсә күрсәтелә? Халык һәм кеше, кешенең язмышы – халык язмышы, менә шуның өчен дә Шекспир бөек ул», – ди.

*(Мәкалә беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналының 1939 ел, 5 санында басыла – К. Г.).*

## Галиәсгар Камал

*(Үлүенә 5 ел тулу уңае белән)*

Татар совет драматургы Галиәсгар Камалның үлүенә 16 июньдә биш ел тулу белән бергә, аның тууына да быел алтмыш ел тула. Шулай ук «Бәхетсез егет» драма әсәрен язуына 40 ел тулды. Галиәсгәр Камал безгә «Бәхетсез егет», «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Көндәш», «Уйнаш», «Банкрот», «Дәҗҗал», «Кайниш», «Безнең шәһәрнең серләре», «Өйләнәм, ник өйләндем», «Өч тормыш», «Хафизалам иркәм», «Җан Таһир белән җан Зөһрә» һәм бик күп санда башка әсәрләр мирас итеп калдырган язучы. Галиәсгар Камал, һичшиксез, татарның зур талантлы драматургы. Татар драматургиясе Галиәсгар Камалга кадәр үк башланган булса да, аны башка милләтләр драматургиясе белән беррәттән куярлык хәлгә китерүче ул булды. Чөнки аңа кадәр язылган драма әсәрләре, кирәк күләм ягыннан, кирәк художество ягыннан, ифрат дәрәҗәдә зәгыйф... әсәрләр иде.

Галиәсгар Камал «Бәхетсез егет», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек киң колачка ия булган зур полотнодагы әсәрләр тудырды. Галиәсгәр Камал байлардан, милләтчеләрдән ачы иттереп көлде. Ләкин ул үзе тәнкыйть иткән буржуаз дөньясындагы төп

Чыганак: Гыйззәтов, К. Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр, Хатлар. Бәхәсләр.- Казан: Мастер Лайн, 2000.- 512 б.



сәбәпләрнең тамырын марксизм-ленинизм нигезендә ача алмады, хезмәт иясенә эксплуататорлар белән ничек көрәшергә кирәклеге турында юл күрсәтә алмады. «Дәҗҗал» әсәрендә ике приказчик арасында көрәшне «яхшы» кеше белән «начар» кеше арасындагы көрәш иттереп кенә бирә...

«Безнең шәһәрнең серләре» әсәрендә Казан буржуа җәмгыятен ачы тәнкыйть астына алып, художество югарылыгында күз алдына китереп бастыра... Галиәсгар Камал, бай, мещан тормышын рәхимсез рәвештә тәнкыйть итеп, оста юмор белән көлде.


*Т. Гыйззәт. 1942 ел.*

Буржуаз милләтче тәнкыйтьчеләр Галиәсгар Камал әсәрләрен художество ягыннан көчсез, зәгыйфь әсәрләр дип бәя бирделәр. Ләкин 1905 елгы революциядән соң бөек Октябрь революциясенә кадәр чорда язылган театр әсәрләре арасында Галиәсгар Камал әсәрләре белән тиңләшерлек бер генә театр әсәре дә юк. «Бәхетсез егет», «Безнең шәһәрнең серләре», «Беренче театр», «Бүләк өчен», бигрәк тә бик зур бәягә ия булган «Банкрот» әсәрләре зур мастерлык белән язылган матур әсәрләр.

Галиәсгар Камал, драматург булу белән бергә, ул заманның зур җәмәгать эшлеклесе дә иде. 1905 елгы революциядән соң «Азат халык» исемле газета һәм халык шагыйре Габдулла Тукай белән берлектә «Ялт-Йолт» исемле журнал чыгара. Татар театрын оештыруда, клуб, китапханәләр ачуга якыннан катнашып, аларның идарәләренә җитәкче булып сайлана. Татарның реакцион муллаларыннан, байларыннан, «милләт хадимнәреннән» ачы итеп көлә. Аларның колакларыннан өстерәтеп масса каршына, халык алдына чыгарып бастыра. Шуның өчен дә аны татар буржуазиясе яратмады, татар милләтчеләре язучы итеп танымады, аның язган әсәрләрен санламыйча, хурлап көлделәр, урамнан узган чакларында ташлар атып калдылар. Хәтта аны кыйнатып имгәтү яисә үтерү теләге белән караңгы почмакларга кешеләр яллап куйдылар. Галиәсгар Камал,

Бөек социалистик революция булу белән Совет платформасына баскан культура көчләренең берсе иде. Ул һич икеләнмичә Октябрь революциясе ягында булып, татар буржуазиясенә каршы кискен көрәш ачучы булды.

1918 елда контрреволюцион милләтче, алпавыт, бай балаларының «кулак җәмгыяте» күтәрелешенә болай дип бәя бирде:

Уйлаганнар иде бугай хан куярга,
Яшел төскә һәрбер флагны буярга,
Сизеп алгач Совет аларның уйларын,
Бирмәде бай малайларына ирек уйнарга.

Гражданнар сугышы чорында, ак бандаларның төрле яктан яшь Совет хөкүмәте өстенә ташланган бер вакытында, Галиәсгар Камал совет матбугатында эшләде, иң җаваплы мәкаләләрне русчадан татарчага тәрҗемә итте. Шул ук вакытта көннең кадагына суга торган:

Киләчәктә якты тормышның чибәре,
Берләшкәндә бөтен дөнья эшчеләре,
Телегездә тәсбих булып йөрсен:
«Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре!» –
дип шигырьләр дә язды.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соңгы елларда татар контрреволюцион милләтчеләре Шәрекъны мактап, Шәрекъ культурасына йөз тотканда, Галиәсгар Камал аларга каршы позициядә торды. Бөек рус халкының һәм дөнья классик драма әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, татар хезмәт ияләре арасында аларны популярлаштырырга ярдәм итте. Ул А. Н. Островскийның «Гроза»сын, «Гаепсез гаеплеләр»ен, Максим Горькийның «Тормыш төбендә», Н. В. Гогольнең «Ревизор»ын, дөнья классикларыннан Мольерның «Скапен хәйләләре», «Ирексездән табип», «Хаста», «Саран Хәмид», Лопе-де-Вега әсәрләрен һәм бик күп санда башка әсәрләрне тәрҗемә итте.

Ул, язучы-драматург булу белән бергә, татар театрын төзүгә, аны үстерүгә бик зур көч куйды. Кара реакциянең каты хөкем сөргән чорында, динче-фанатиклар тарафыннан театрга мәрхәмәтсез һөҗүм иткән бервакытта, актерлар кадры хәзерләүгә әһәмият биреп, үзенең ике туганы – Габдулла Камал, Габдерахман Камалларны татар сәхнәсенә артист итеп бирә... Алафузов заводы каршында эшчеләр труппасы оештырып, үзе дә артист була һәм режиссерлык итә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Мехкомбинат клубында, сукырлар мәктәбендә җитәкче, режиссер булып эшли.

Галиәсгар Камал тормыш юлы менә шулай. Ул бөтен көчен хезмәт иясен тәрбияләүгә, культура, аң-белем бирүгә сарыф итә.



Шуның өчен дә Совет хөкүмәте 1928 елны аның 30 еллык хезмәт бәйрәмен үткәреп, ана Хезмәт Герое исемен бирде. Үзенең бәйрәм көннәрендә бөтен Советлар Союзындагы шәһәрләрдән котлау телеграммалары килгәндә, элекке вакытта аңардан көлеп, аның әсәрләрен санга сукмый йөргән Гаяз Исхаков та котлау телеграммасы җибәрә. Галиәсгар Камал бу телеграммага «Кызыл Татарстан» газетасы аша болай дип җавап бирде:

«Иптәш редактор!

Мин шушы хатыма газетагызда урын бирүегезне үтенәм. Минем 30 еллык хезмәт бәйрәмем уңае белән бәйрәмгә катнашкан, мине тәбрикләгән оешмалар, аерым иптәшләр, театр һәм концерт көчләренә катнашкан артист-артисткаларга һәм ул концертны оештырган иптәшләрнең һәммәсенә тәшәккеремне белдерәм.

Шуның белән бергә, ирекле Совет иленең дошманнары, контрреволюциясе татар ак эмиграциясе тарафыннан җибәрелгән тәбрик телеграммасын үзем өчен тәбрик түгел, бәлки хурлык санаганымны әйтеп үтәргә тиеш табам. Минем 30 еллык хезмәтемнең 12 елы ирекле Совет дәүләтендә үтте. Бу 12 елның киң мөмкинлекләр бирүе ягыннан башкаларга чагыштырмаслык аермалары бар. Шуна күрә Гаяз әфәнделәр көткән «ирек»нең минем өчен һич кирәге булмаганын, үземнең андый «ирек»ләрнең чын дошманы булуымны белдерәм».

Галиәсгар Камал һич икеләнмичә революция ягында булып, гомеренең ахыргы көненә кадәр Совет платформасында армый-талмый эшләде.

Без аның калдырган бай мирасыннан файдаланырга тиешбез һәм һәрбер театрның репертуарында Галиәсгар Камал әсәрләре күренекле урын алырга тиеш.

Татар дәүләт академия театры Галиәсгар Камалның үлүенә 5 ел булу уңае белән, аның иҗатын Уфа хезмәт ияләренә таныштыру теләге белән 19 июньдә «Банкрот» исемле комедиясен Культура сараенда куя башлады.

*(Мәкалә беренче тапкыр Башкортстанда «Коммуна» газетасында 1938, 20 июньдә басыла – К. Г.).*

## Шәриф Камал белән саубуллашу

Без бүген, йөрәкләребез әрнегән хәлдә, татар совет әдәбиятының гигант фигурасы булган Шәриф абый Камал белән бәхилләшәбез... Без бүген, бәгырьләребез сыкранган хәлдә, татар совет сәнгатенең эшлеклесе Шәриф абый Камал белән бәхилләшәбез... Без бүген,